**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 26.06.2020

КАРАР
№ ПР-129

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында “Гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) булдыру турында” 2017 елның 6 апрелендәге ПР-67 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 30 сентябрендәге 1274 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) булдыру турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 6 апрелендәге ПР-67 номерлы карарының 3 нче кушымта 8 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «гражданнар оборонасы буенча билгеләнгән тәртиптә кертелгән оешмаларга яктылык маскировкасы һәм башка төр маскировка буенча чаралар уздыру өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын билгеләү буенча даими файдалануга әзер булган оешмаларны булдыру һәм аларга ярдәм итү;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И. Габдулхаев